ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕПИНЯЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ ПӘНӘЧЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**03.02.2026 г.** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 06 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «2026 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәте 2026 елның 23 гыйнварындагы 30 номерлы карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Уставына таянып,

**карар бирәм:**

1. 2026 елның 01 февраленнән Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 9678,63 сум күләмендә, 1-нче һәм 2-нче кушымталар нигезендә, билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. “Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында” 2025 елның 31 гыйнварындагы 03 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 февраленнән барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Югары Пәнәче авыл җирлеге**
**Башкарма комитет җитәкчесе** **М. Х. Туктаров**

Зәй муниципаль районы
Югары Пәнәче авыл җирлеге
башкарма комитетының
03.02.2026 ел 3 номерлы
карарына
1 нче кушымта

2026 елның 01 февраленнән
Югары Пәнәче авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3 681,24 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1 573,46 |
| 4. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4 423,93 |
| Барысы | 9 678,63 |

Зәй муниципаль районы
Югары Пәнәче авыл җирлеге
башкарма комитетының
03.02.2026 ел 2 номерлы карарына
2 нче кушымта

2026 елның 01 февраленнән
Югары Пәнәче авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 1009,41 |
| 3. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 747,27 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1 535,83 |
| 5. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4 386,12 |
| Барысы | 9 678,63 |